| СОВЕТ ИСЕРГАПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСЕРГӘП АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 февраль 2019г. Исергәп авылы № 91

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы**
**Исергәп авыл җирлеге территориясендә**
**«Гражданнарның үзара салымы турында»**
**Нигезләмәсен раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Исергәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:
1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының» «Исергәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә «Гражданнарның үзара салымы турында» Нигезләмәсен расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 гыйнварынын «Исергәп авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым салу турында»51 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга" .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә.

Авыл җирлеге Башлыгы,
Совет председателе Әглиуллин А.А